МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.06.2024 Казан ш № 442

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә социаль хезмәтләрдән файдалануга гражданнар чиратын формалаштыру һәм алып бару тәртибен раслау турында» 2020 елның 03 июлендәге 484 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә социаль хезмәтләрдән файдалануга гражданнар чиратын формалаштыру һәм алып бару эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә социаль хезмәтләрдән файдалануга гражданнар чиратын формалаштыру һәм алып бару тәртибен раслау турында» 2020 елның 03 июлендәге 484 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 24.02.2021 ел, №100, 27.01.2022 ел, №58 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

боерык преамбуласына «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүчеләр тарафыннан ярымстационар рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» сүзләреннән соң «, Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүчеләр тарафыннан өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 29.12.2014 ел, №1053» сүзләрен өстәргә;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә социаль хезмәтләрдән файдаланугa гражданнар чиратын формалаштыру һәм алып бару тәртибендә:

1.1 пунктта «(алга таба - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 31.12.2014 ел, №1101 карары)» сүзләреннән соң «, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүчеләр тарафыннан өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 29.12.2014 ел, №1053 карары (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 29.12.2014 ел, №1053 карары)» сүзләрен өстәргә;

2.7 пунктның икенче абзацында «(ярымстационар) социаль хезмәт күрсәтү» сүзләреннән соң «, өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә» сүзләрен өстәргә;

3.1 пунктта «31.12.2014 ел, №1101» сүзләреннән соң «29.12.2014 ел, №1053» сүзләрен өстәргә;

3.3 пунктның икенче абзацында «психоневрологик интернатлар, акыл ягыннан артта калган балалар өчен балалар интернат-йортлары» сүзләрен «психик тайпылышлы гражданнар өчен билгеләнгән интернат-йортлар, психик тайпылышлы гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат-йортлары» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданинда, ул булган очракта гражданинга, шул исәптән вакытлыча да, өйдә яки ярымстационар рәвешендә, яки стационар рәвештә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләрне күрсәтүдән Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Гражданинга яки социаль хезмәтләрне алучыга, алар булына бәйле рәвештә, шул исәптән вакытлыча да, өйдә яки ярымстационар рәвешендә, яки стационар рәвештә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләрне күрсәтүдән баш тартылырга мөмкин булган медицина каршылыклары исемлеген, шулай ук мондый медицина каршылыклары булуы (булмавы) турында вәкаләтле медицина оешмасы бәяләмәсе формасын раслау турында» 2023 елның 2 маендагы 202н номерлы боерыгы белән расланган исемлектә күрсәтелгән медицина каршылыклары булуына рәвештә баш тартылырга мөмкин булган медицина каршылыклары булуына бәйле рәвештә;

2 нче кушымта искәрмәсендә* «31.12.2014 ел, №1101» сүзләреннән соң «29.12.2014 ел, №1053» сүзләрен өстәргә.

Министр Э.Ә. Зарипова